Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

29.09.2022 ел

Менделеевск ш.

№579

Җир кишәрлегеннән файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 2 августындагы 60 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 2 ноябрендә 16 сәгатьтә Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының административ бинасында түбәндәге адрес буенча: Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 йорт, актлар залында 16:27:110149:26 кадастр номеры булган Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Менделеевск шәһәре, Яр буе урамы, 57 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәте (җир кишәрлеген шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен «Кибет» белән файдалануның рөхсәт ителгән төрен үзгәртү) бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру комиссиясен түбәндәге составта төзергә:

Искаков А.Ф. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе;

Сергеев В.В. - «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе башлыгы вазифаларын башкаручы ;

Хәбиров Р.З. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитектор хезмәте архитекторы;

Антоновская Н.И. - Менделеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча).

3.2022 елның 30 сентябреннән 2021 елның 2 ноябренә кадәр «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы хезмәте бүлегендә җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча материаллар экспозициясен түбәндәге адрес буенча оештырырга: Менделеевск ш., Фомин ур., д19 (5 кат).

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 432650, Татарстан Республикасы, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 йорт («Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы исеменә).

5.Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга http://Mendeleevsk.tatar.ru.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы Р.З. Хәбировка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы С.В. Метальников

Килештерелде
Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Баш архитектор хезмәте архитекторы Р.З.Хәбиров